## УКЫТУНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

5-9 сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның планлаштырылган **нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- туган илгә мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- милли үзаң формалаштыру;
- укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру;
- әйләнә-тирә табигатькә дөрес караш булдыру;
- кешеләр белән аралаша белү культурасы тәрбияләү;
- гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү;
- алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

**Танып-белү гамәлләре:**

- әдәби әсәрне дөрес аңлап уку һәм анализлау;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.

**Коммуникатив гамәлләр:**

- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;
- нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыру;
- текст буенча сораулар бирә белү.

**Регулятив гамәлләр:**

- дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль таба белү;
- укыту проблемасын чишү;
- план буенча эшли белү;
- үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү;
- үзанализ һәм үзбәя булдыру.

**Предмет нәтиҗәләр:**
- халык авыз иҗаты әсәрләрен үзләштерү, аның матур әдәбият белән уртак сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен аера белү;
- әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау, төп фикерне таба белү;
- әсәрләрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау;
- язучыларның тормыш һәм иҗат юлларының мөһим фактларын истә калдыру;
- әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә теоритек белемгә ия булу;
- әсәрдә автор карашларын ачыклау һәм әсәргә карата үз фикереңне әйтә белү;
- әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлау.

## УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМЕНӘ, ЭШ ОСТАЛЫГЫНА ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕНӘ ТАЛӘПЛӘР

(әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр)

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә **укучы белергә тиеш**

- сүз сәнгатенең образлы табигатен;
- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларыннан Г.Тукайның, Г.Камалның, Г.Ибраһимовның, Ф.Әмирханның, Г.Исхакыйның, М.Җәлилнең, Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын;
- өйрәнелгән әсәрләрнең эчтәлеген;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- төп әдәби-теоретик төшенчәләрне

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы мәктәпне тәмамлаучы **өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап, аерым өлешләрен яттан сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең аерым якларын элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын билгеләү;
- әдәби әсәрләрне, аларның геройларын чагыштыру;
- геройларга характеристика бирү, автор позициясен ачыклау;
- сәнгатьле уку;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару
- әдәби текстның эстетик һәм әхлакый кыйммәтләрен аңлый, фикерен белдерә ,
- укылган (тыңланган) әсәр буенча рәсемнәр, проектлар, презентацияләр ясый,
- укылган (тыңланган) әсәрләрне сәхнәләштерә, төркемнәрдә эшли.

## Укыту предметының эчтәлеге

Урта сыйныфларда әдәбият укыту әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты белән укып танышу һәм аларны өйрәнү, тикшерү–анализлау һәм нәтиҗәләр ясауга, бәяләүгә йөз тота. Укучыларда язучыларның тормышы, иҗаты турында (биографик), әдәбият тарихы, аның төрле этаплары, аерым чорлар әдәбиятының йөзен билгеләгән әсәрләр, язучылар турында өстәмә, әдәби әсәрне, иҗатны тирәнтен анализлау өчен кирәк булган өстәмә теоретик, әдәби әсәрне чор белән бәйләп характерлаучы, чорның сыйфатларын, төп кыйммәтләрен табу өчен кирәкле мәгълүматларның туплануы мөһим.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятының аерым чорлары үзара бәйләнешле өйрәнелә башлый, аерым фольклор үрнәкләре, аларга анализ аша поэтик-фәлсәфи йөкләмәне, эчке, субъектив мәгънәне табу күнекмәләре формалаштырыла – болар әдәби иҗатка карата күзаллау булдыруда катнаша. Әдәби үрнәкләр белән танышу эше өч төрдә алып барыла: аерым әдәби әсәрләр уку һәм анализлау, аерым берләре укып фикер алышу, кайберләре сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителә. Әмма һәр очракта да алда куелган критерий һәм таләпләр истә тотыла.

## Әдәбият тарихы

***Әдәбият тарихын*** өйрәнү халык авыз иҗатыннан башлана.

**Халык авыз иҗаты**

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең үзенчәлекле сыйфатлары, аларда гомумкешелек кыйммәтләренең зур урын тотуы. Халык авыз иҗатында образлар бирелеше. Фольклорда дөнья сурәте: каһарманлык, яхшылык һәм явызлык, яшәеш һәм кеше, кеше һәм табигать хакында күзаллаулар.

Халык иҗатының язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынты ясавы. Фольклорның төп жанрлары. Әкиятләр, жанрлык сыйфатлары, жанр төрләре. Җыр жанрына хас сыйфатлар. Җырларны төркемләү. Татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүз. Кыска жанрлар: табышмаклар, мәзәкләр, мәкальләр һәм әйтемнәр. Бәетләр. Риваятьләр һәм легендалар, аларга хас үзенчәлекләр. Мифлар. Мифларның килеп чыгышы хакындагы карашлар. Мифларны төркемләү. Татар халык мифлары. Дастан жанрына хас сыйфатлар.

Халык авыз иҗаты поэтикасы (фантастик яки мифологик сюжет һәм детальләрдәге чынбарлыкка охшату; сурәтләү чаралары буларак кабатлау, каршылык, чиктән тыш арттыру, кечерәйтү, чагыштыру һ.б.). Татар халык авыз иҗатының башка халыклар фольклоры белән аваздашлыгы һәм аермалы яклары.

Әдәбиятның барлыкка килүе, татар әдәбиятының фольклор һәм ислам мифологиясе белән бәйләнешләре. Фольклор жанрларының әдәбиятка күчүе.

**Борынгы, урта гасырлар һәм XIX гасыр татар әдәбияты**

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Тотрыклы мотивлар: гадел идарәче, мәрхәмәтлелек, игелекле исем–ат, әхлаклылык, камил инсан һ.б. Урта гасырлар әдәбиятында романтик мотивлар. Үгет–нәсыйхәтчелек.

Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уянырга, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.

**XX йөз — XXI йөз башы татар әдәбияты**

XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.

1920-1930 елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр. Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте.

XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы.

XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау.

Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар.

**Әдәбият теориясе**

**Әдәби төр һәм жанрлар.** Эпос, лирика һәм драма төрләре. Жанр. «Жанр хәтере». Эпик жанрлар: роман, повесть, хикәя. Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы, фәлсәфи лирика. Шәркый жанрлар системасы. Драма жанрлары: комедия, трагедия, драма. Лиро-эпик жанрлар: сюжетлы шигырь, мәсәл, баллада, нәсер, поэма. Төрара формалар: сәяхәтнамә.

**Сәнгать төре буларак әдәбият**. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.

**Әдәби әсәрдәге образлылык.** Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Лирик герой, хикәяләүче, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. Табигать образы, әйбер образы, мифологик образ, фантастик образ, архетип.

**Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма.** Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп. Текст: эпиграф, багышлау, көчле позиция.

**Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль.** Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Лирик чигенешләр. Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа. Шигырь төзелеше. Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж. Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар.

**Әдәбият тарихы.** Традицияләр, яңачалык. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият.

**Әдәби барыш.** Әдәби процесс (барыш); чор әдәбияты.

**Күнекмәләр формалаштыру**

Укучыга билгеле бер күләмдә белем бирү белән янәшә, аларны ныгыту, күнекмә дәрәҗәсендә беркетү кирәк була. Әдәбият шикелле белемнәр анализлау-тикшерү барышында үзләштерелә торган предмет өчен бу аерата мөһим. **Күнекмәләр булдыру** эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрдә үстерелә һәм бәяләнә:

- **рецептив эшчәнлек**: әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан сөйләү; сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләү һәм фикерне исбатлау.

- **репродуктив эшчәнлек**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, бәяли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.

- **иҗади эшчәнлек**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; рольләргә кереп кабатлап бирү; план төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә язу, сочинение элементлары белән изложение язу; әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу.

- **эзләнү эшчәнлеге**: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әдәби әсәргә, аның өлешләренә, язучы иҗатына карата аңлатмалар, бәя бирү.

- **тикшеренү эшчәнлеге**: әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау; тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү.

**5 нче сыйныф**

## Халык авыз иҗаты

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык иҗаты. Аның сәнгать төрләре формалашуга йогынтысы. Халык иҗатының бер төре буларак халык авыз иҗаты. Аның әсәрләрендә гомум кешелек хыяллары, идеалларының чагылуы. Халык авыз иҗатының матур әдәбият белән бәйләнешләре: уртаклыгы һәм үзенчәлекле аермалары. Халык авыз иҗатының төп жанрлары, жанр сыйфатлары. Татар халык әкиятләре. Әкиятләр, аларның жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары: тылсымлы, тормыш-көнкүреш, хайваннар турында әкиятләр. “Ак бүре” әкияте (кыскартып). “Үги кыз”, “Аю белән төлке” әкиятләре. Татар фольклорының лирик һәм лиро-эпик жанрлары. Җырлар: татар халык җырларына хас үзенчәлекләр, лирик, тарихи, йола җырлары, такмаклар, мөнәҗәтләр.. Көй һәм сүзләр тәңгәллеге. “Моң” төшенчәсе. Җырларны төркемләү. “Иске кара урман”, ”Гөлҗамал”,”Туган ил”,”Яшә, Республикам!”,”Ай былбылым”; кыскаҗырлар - дүртюллыклар; тарихи җырлар: “Болгар иленең кызлары”,”Пугач явы”. Фольклор әсәрләрендә халыкның психологиясе, идеаллары, күзаллаулары. Кыска жанрлар: мәкальләр һәм әйтемнәр. табышмаклар, мәзәкләр. “Хуҗа Насретдин мәзәкләре”. Татар фольклорының үзенчәлекле жанры буларак бәетләр, аларга хас үзенчәлекләр. “Сак-Сок” бәете. Жанр формалашуның алшартлары, аларның төрләре, төркемчәләре. Татар фольклорының эпик жанрлары. Риваятьләр, легендалар: аларга хас үзенчәлекләр; жанр сыйфатлары.“Янмый торган кыз”,”Иске Казан каласының корылуы”,”Шәһәр нигә Казан дип аталган”,”Әллүки”,”Зөһрә кыз”,”Кеше гомере ничек корылган”. “Зөһрә кыз” легендасы. Халык авыз иҗаты поэтик үзенчәлекләре: фантастик яки мифологик сюжет һәм детальләрдәге чынбарлыкка охшату; сурәтләү чаралары буларак кабатлау, каршылык, чиктән тыш арттыру, кечерәйтү, метафора, аллегория, җанландыру, чагыштыру һ.б. Героик эпос. Дастан жанрының характерлы билгеләре. Халык авыз иҗатында образлар; әсәрләрдә дөнья сурәте; табигать һәм кеше, яшәеш һәм кеше турында күзаллаулар. Халык авыз иҗаты поэтикасы, язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынтысы. Татар халык авыз иҗатының башка халыклар фольклоры белән аваздашлыгы һәм аермалы яклары.

## Әдәби әкиятләр

Әдәби әкиятләр: халык әкиятләре белән уртаклык; сәнгатьлелек сыйфатлары, әдәби әсәр буларак алым һәм сурәтләү чаралары. Г.Тукайның “Шүрәле” әкияте. Фольклор әкиятләре һәм әдәби әкиятләр. Сәнгатьчә уйдырма, троплар. Ж.Тәрҗемановның “Тукран малае Шуктуган” әкияте. Әхмәт Фәйзинең “Аучы мәргән белән Болан кыз” әкияте. Рабит Батулланың “Курай уйный бер малай” әкияте. Фәнис Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена”, “Кояштагы тап” әкиятләре

**XX йөз – XXI йөз башы әдәбияты**

Хикәя: жанр сыйфатлары; әсәрнең катламнары – вакыйгалар, күренешләр, хис-кичерешләр; кеше образлары - төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар; хикәяләүче образы, автор
позициясе.Фатих Әмирханның “Ай өстендә Зөһрә кыз”,”Нәҗип” хикәяләре. Әдәбиятның барлыкка килүе, татар әдәбияты белән фольклорның һәм ислам мифологиясенең бәйләнеше. Фольклор жанрының әдәбиятка күчүе. Ф.Әмирханның “Ай өстендә Зөһрә кыз” хикәятендә яхшылык һәм явызлыкның җанлануы. Әсәрдә персонажлар системасы. Авторның вакыйгаларга мөнәсәбәте. Хикәятнең сәнгатьчә эшләнеше. Хикәя турында төшенчә. Мәсәл. Тереклек, җансыз предмет образлары ярдәмендә, читләтеп, кеше сыйфатларын һәм тормышын тасвирлау. Хикәяләп яки тезмә рәвештә язылуы; фикер-идеяләрнең аллегория ярдәмендә белдерелүе. Мәҗит Гафуриның “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле, аллегорик образлар. Габдулла Тукайның “Ике сабан” мәсәле. Сәнгать төре буларак матур әдәбият; чәчмә һәм тезмә әсәр; аларның сәнгатьчә сурәтләү алымнары, чаралары. Шигърият. Габдулла Тукайның “Пар ат”,”Туган җиремә”,”Туган авыл” шигырьләре. Фольклор әкиятләре һәм әдәби әкиятләр. Сәнгатьчә уйдырма, троплар, лирик герой. Романтик шигырьләрдә туган җиргә мәдхия. Казанга баруның әкияти тасвирланышы. Туган җирне һәм Казанны мифлаштыру. Шәүкәт Галиев. Балалар әдәбиятындагы урыны; геройлары, образлар дөньясы. Юмор һәм сатира, шигырь, шигырь төзелеше, тезем. “Һәркем әйтә дөресен”,”Тереклек суы”, ”Курыкма, тимим!”, “Тарихтан сабак”,”Өйгә бирелгән эш”,”Онытылган, өйдә калган” шигырьләре.
Барлыгы : 35 сәг**.**

**6 сыйныф**

**Халык авыз иҗаты**

Фольклорның эпик жанрларын кабатлау: бәетләр, әкиятләр, риваять, легендалар. Метафора, аллегория. Мифлар. Мифларның килеп чыгышы хакындагы карашлар. Мифларны төркемләү. Татар халык мифлары. “Алып кешеләр” мифы. “Җил иясе җил чыгара” мифы. Әдәбиятның барлыкка килүе, татар әдәбиятының фольклор һәм ислам мифологиясе белән бәйләнешләре.

Әдәбиятта мифологик һәм дини сюжетларның үсеше

К.Насыйриның фәнни һәм әдәби эшчәнлеге. Аның татарларның тарихын, әдәбиятын, этнографиясен, фольклорын өйрәнүе. “Әбүгалисина” повесте. Эпос. Повесть турында төшенчә. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. К.Насыйриның “Әбүгалисина” повестеның фантастик сюжеты һәм мәгърифәтчелек идеяләре. К.Насыйриның “Әбүгалисина” повестендагы образлар. Фантастик образ. Әбүгалисина һәм Әбелхарис образларына чагыштырма характеристика бирү. “Әбүгалисина образы – тарихи персонаж, әкияти герой яки мәгърифәтчелек идеалымы?” темасына фикер алышу.
Фольклор жанрының әдәбиятка күчеше

Г.Рәхимнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Яз әкиятләре” хикәясе. Фольклор жанрларының әдәбиятка күчүе. Шартлылык. Аллегорик образлылык. Хикәяләүче – персонаж исеменнән сөйләү. Автор образы, автор позициясе. Эчкерсезлек сыйфатының кешедәге мөһим сыйфат булуын раслау. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья.

Г.Ибраһимов

Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Алмачуар” хикәясе. Пейзаж. Этнографик детальләр һәм материаллар, татар авылы образы чагылышы. Халык тормышының матурлыгын, әхлакый бөтенлеген чынбарлыкның гармониясендә чагылдыру. Г.Ибраһимовның “Алмачуар” хикәясендә Алмачуар һәм кеше образлары системасы. Кечкенә геройның атларга мәхәббәте. Өлкән хикәяләүче һәм сөйләүче-малай образларның функцияләре. Хикәяне өйрәнүне йомгаклау.

Г.Тукай

Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. “Исемдә калганнар” автобиографик истәлеге.  Биография һәм автобиография. Хикәяләүче образы: кечкенә Апуш һәм шагыйрь Габдулла. ”Исемдә калганнар” әсәре. Автор образы. Характер, истәлекләр, шартлылык, уйдырмалар. ”Исемдә калганнар” әсәрен йомгаклау.

Р.Батулла

Р. Батулланың тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Имче” хикәясе. Тукайның балачагы турында тарихи сюжет. Тарихи ситуацияләрне тудыру алымнары, сөйләм үзенчәлекләре. Р. Батулланың “Имче” хикәясендәге образлар. Батулланың герое белән Тукайның Апушы арасында охшашлык һәм аермалар.

Г.Камал

Галиәсгар Камалның тормыш юлы, иҗаты – татар реалистик драматургиясенә нигез салучыларның берсе. “Беренче театр” әсәре. 1905-1907 еллар инкыйлабы тудырган шартларда драматургиянең, татар театрының үсеше. Драма жанрлары. “Беренче театр” әсәрендә төп конфликтлар. Искелек һәм яңалык көрәше. Конфликт турында төшенчә. Мәгърифәтчелек идеяләре һәм көлү чаралары. Галиәсгар Камалның “Беренче театр” әсәрендәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру. Персонаж, характер, тип. Комик образлар.

Дәрдмәнд

Дәрдмәнднең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Татар әдәбиятында Дәрдмәнд турында. “Видагъ” шигыре. Лирика. лирик “мин”. Лирик әсәрнең эчтәлеге, лирик герой, хис- кичереш. Лирик геройның күңелен ачу чарасы буларак Табигать образы. Пейзаж лирикасында фәлсәфи мәгънә, символлар. Лирик-эмоциональ образлар.

С.Рәмиев

С.Рәмиевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Татар әдәбиятында С.Рәмиев турында. “Уку” шигыре. Мәгърифәтчелек мотивлары. Автор образы. Гражданлык лирикасы.

Һ.Такташ

Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Пи-би-бип” шигыре.Табигать һәм туган җир образы.

М.Җәлил “Сандугач һәм чишмә” балладасы. Шартлылык, аллегория.

Барлыгы : 35 сәг**.**

**7 сыйныф**

## Образлар системасы. Деталь һәм образ

### Халык авыз иҗаты

“Идегәй” дастаны. Дастан жанрына хас үзенчәлекләр. Дастанның кыскача эчтәлеге, проблематикасы, төп геройлар. Тотрыклы мотивлар: гадел идарәче, мәрхәмәтлелек, игелекле исем-ат, әхлаклылык, камил инсан.

### XX йөз - XXI йөз башы татар әдәбияты.

XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. Әдәбиятның эпик төре. Эпик жанрлар. Хикәя жанры. Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Яшь ана” хикәясе. Татар әдәбиятында кыз һәм үги ананың традицион булмаган сюжеты. Үги ана образының мәгънәви йөкләмәсе. Әсәрнең теле һәм сәнгатьчә үзенчәлеге. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст

Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. “Милләтә”, “Милли моңнар” шигырьләре. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Әдәбиятның лирик төре. Лирика һәм лиро-эпика. Гражданлык лирикасы. Шигырьнең диалогик формасы. Милләткә мөрәҗәгать, үз халкыңа мәхәббәтне күрсәтү. “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре.

Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Акчарлаклар” повесте. Повесть жанры. Ш.Камалның “Акчарлаклар” повесте.. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар. Ш.Камалның “Акчарлаклар” повестеның әһәмияте һәм актуальлеге. Чит җирдә бәхет эзләргә мәҗбүр булу проблемасы. Драматизм. Символ. Сәнгатьчә сөйләм, хикәяләү, монолог, диалог.

Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Мокамай” әсәре.

Лиро эпик жанр.

Г.Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты.

Татарларда драма төре, жанрларының барлыкка килү тарихы. “Җан Баевич” комедиясе. Әсәрнең сюжет- композициясе. XX гасыр башында татар җәмгыятендә барлыкка килгән көлкеле вакыйгаларны, аерым кешеләрнең белемле күренергә тырышып, русларның көнкүрештәге тышкы атрибутларын кулланып, үзләренең чыгышларын, телләрен онытулары турында сурәтләү. Сатира һәм ирония. Әсәрнең образлар системасы. Әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен билгеләү.

Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Кызыл чәчәкләр” повесте, повестьның сюжеты. Ватан, ил, халык образларының эпик гәүдәләнеше. Әдәби әсәрнең төре, жанры, проблемасы.

Өлкән буын шагыйрьләренең иҗатында мәдәни, әдәби, тарихи тәҗрибә турында лирик һәм социаль – фәлсәфи фикерләү. С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Әнкәй” шигыре. Лирик герой. Күңел лирикасы. Лириканы психологик детальләр белән баету. С.Хәкимнең “Бу кырлар, бу үзәннәрдә” шигыре. Туган як образы. Ватан образын мифлаштыру. Пейзаж лирикасы. Табигать образы.

Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗаты. “Әйтелмәгән васыять” повесте. Сүз сәнгатендә милләт проблемасының алгы планга чыгуы. Әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару. Милли һәм социаль проблематика. Татар милләтенең тарихы турында

уйланулар, җәмгыятьтә әхлакый ориентирларның югалуы. Пейзаж, портрет. Эпиграф, багышлау, көчле позиция. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья.

Ш.Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Әни килде” драмасы. Социаль- этик проблематика. Образ, символ, архетип. Драматургия һәм прозада тәнкыйди юнәлешнең формалашуы. “Әни килде” драмасының сюжеты, сюжет элементлары. образлар системасы. Драма. Драманың әһәмияте. .

Татар әдәбиятында бәхет мотивы. Г.Сабитовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Тәүге соклану” хикәясе. Авыл тормышы картинасы, хикәянең сюжеты. Көнләшү нәтиҗәсе буларак конфликт. Балачакны, үткәнне сагыну. Хикәяләүче малай һәм автор – хикәяләүче. Вакыйга, подтекст, контекст. Алтын балык, ак болыт символы.

З.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Сәер кыз”драмасы. Драманың сюжеты, образлар системасы. .

М.Мәһдиевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Без – кырык беренче ел балалары” повесте.Татар прозасында лиризм һәм орнаментализм, лирик чигенешләр. Әдәбиятның төрле үсеш чорларында тема һәм мотивларның кабатланышы.Татар әдәбиятының ХХ йөз башында, ХХ йөзнең икенче яртысында милләт язмышы мотивы. М.Мәһдиевның “Без - кырык беренче ел балалары” повестенда образлар. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт. .

М.Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Уйна әле”хикәясе. Образлар системасы. Әйбер образы.

Г.Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Язмышның туган көне” хикәясе. Сурәтләнгән дөнья, пейзаж, портрет, психологизм, хронотоп. Г.Гыйльмановның “Язмышның туган көне” хикәясенең сюжеты һәм образлар. “Могҗиза көтү мизгеле сезгә танышмы?” темасына фикер алышу.

Р.Харисның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү. “Сабантуй” поэмасы. .

Равил Фәйзуллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь”, “Онытма син!” шигырьләре.

Әдәби төрләрне, жанрларны, әдәбият теориясен ныгыту

Барлыгы : 70 сәг.

**8 сыйныф**

**Матур әдәбиятның төрләре: лирика, эпос, драма**

Урта гасырлар әдәбиятында дини-суфичыл әсәрләр

Суфичылык һәм суфичылык әдәбияты. Матур әдәбиятта нәсыйхәт. Казан ханлыгы чоры әдәбиятына гомуми характеристика (Мөхәммәд Әмин, Кол Шәриф, Өмми Камал). Мөхәммәдьярның тормыш һәм иҗат юлы турында белешмә, гуманлы дидактик иҗаты. “Нәсыйхәт” шигыре.

**Мәгърифәтчелек әдәбияты** .

Белемле, мәгърифәтле кеше сурәтләү үзенчәлекләре концепциясе. М.Акъегетнең тормыш һәм иҗат юл турында белешмә. “Хисаметдин менла” повесте. М.Акъегетнең “Хисаметдин менла” повесте. Композиция: эчке һәм тышкы корылыш. Әсәрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше. Мәгърифәтлелек, намуслылык, акыл, патриотизм һәм игелеклелек. Геройга автор характеристикасы. Геройның әхлакый үзенчәлеге. Хисаметдин образында халыкның идеаль сыйфатлары гәүдәләнеше

**XX гасыр башы татар әдәбиятында дини-суфичыл әсәрләр**

XX гасыр башы татар әдәбиятының үзенчәлеге. XX гасыр башы татар әдәбиятында дини- суфичыл әсәрләр. М.Гафуриның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә.”Нәсыйхәт” шигыре. Шагыйрьнең XX гасыр башы шигъриятендә яхшылык һәм яманлык, традиция һәм яңалык. Г.Тукай иҗатында дин фәлсәфәсе. “Тәэсер”, “Ана догасы”, “Таян Аллага”, “Нәсыйхәт” шигырьләре

**XX гасыр башы татар әдәбиятында психологизм**

Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Буранда” хикәясе. Хикәянең эмоциональ бирелеше: чаралар һәм алымнар, композиция.Хикәяләүче образы. Трансцендентальлек. Көчле позиция

XX **гасыр башы татар әдәбиятында сызлану фәлсәфәсе**

Ф.Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Бер хәрабәдә” хикәясе. Хикәяләүче образы, аның кичерешләре. Геройлар, аларның исемнәре. Символ, кабатлау, текстның музыкальлелеге. Нәсер жанры.

**20-30 нчы еллар әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе**

XX гасыр башы татар әдәбиятында романтизм, мәхәббәт фәлсәфәсе. Ф. Бурнашның тормышы һәм иҗаты турында белешмә. “Таһир-Зөһрә” трагедиясе.Трагедия. Урта гасыр романтик сюжеты. Мәхәббәт һәм хыянәт темасы.

20-30 нчы еллар әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе һәм яңа тормыш өчен көрәш романтикасы К.Тинчуринның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Сүнгән йолдызлар” драмасы.

Әсәр исеменең афоризмы. Мәхәббәт темасы. “Сүнгән йолдызлар” әсәренең сюжеты, сюжет элементлары. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте. 1920-1930 нчы елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр. Һ.Такташның “Алсу” поэмасы. Поэма жанры. Романтик герой. Г.Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” повесте. Традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой образы. Романтик сюжет. Социалистик реализм рухында сурәтләү.

**Бөек Ватан сугышы һәм әдәбияты**

Ф.Кәримнең тормышы һәм иҗаты. Татар әдәбиятында патриотизм. Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятында патриотизм. “Сибәли дә сибәли” шигыре. Төп герой образын сурәтләүдә табигатьнеңроле. Психологизмның көчәюе. Ф.Кәримнең “Бездә яздыр”, “Теләк”, “Газиз әнкәй” шигырьләре.

**60-80нче еллар әдәбияты**

Г.Бәшировның тормыш юлы һәм иҗаты. “Туган ягым – яшел бишек” повесте. А.Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Язгы кәрваннар” повесте. М.Юнысның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” әсәре.Р.Фәйзуллинның тормышы һәм иҗаты турында белешмә. “Җаныңның ваклыгын сылтама заманга”, “Вакыт”, “Аккошлар”, “Мин сиңа йомшак таң җиле...”, “Якты моң” шигырьләре. Кыска шигырьләр. Гражданлык лирикасы. Татар әдәбиятында фәлсәфилек. Т.Миңнуллинның тормышы һәм иҗаты турында белешмә. “Әлдермештән Әлмәндәр” драмасы. Әдәбиятта көчле кеше образы. Үлемне җиңү мотивы. Яшәү иҗтыяҗы буларак дөньяны үзгәртү. Ф.Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Җилкәннәр җилдә сынала” повесте. Җилкәннәр җилдә сынала” повестеның сюжет-композициясе, биографик характеры. Язмыш һәм шәхси көчсезлек белән көрәшү.М.Әгъләмовның тормыш һәм иҗат юлы турында белешмә. М.Әгъләмов иҗатында жанр формаларының төрлелеге, аның стиль үзенчәлекләре.

“Каеннар булсаң иде” шигыре. “Учак урыннары” шигыре. Күңел лирикасы. Идеалларга тугрылыкта көчлелек. Тарихи истәлек проблемасы.

8 нче сыйныфта үткәннәрне йомгаклау

Барлыгы : 35 сәг**.**

**9нчы сыйныф**

**Әдәбият – сәнгатьнең бер төре**

Сүз сәнгате буларак әдәбият. Сүз сәнгатенең үзенчәлеге. Әдәбиятның формалашуы, шартлары, сәбәпләре. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормышны сәнгатьчә сурәтләү үзенчәлекләре. Матур әдәбият - кешенең рухи дөньясының төрлелеге һәм байлыгы, дөньяны – танып белүнең бер формасы. Тормышны сәнгатьчә чагылдыру. Эстетик һәм әхлакый фикерләр формалаштыруда әдәбиятның тәэсире.

**Борынгы, урта гасырлар һәм XIX йөз әдәбияты**

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Борынгы һәм Урта гасырлар төрки әдәбияты, үсеш этаплары. Гомумтөрки чорда фольклор һәм әдәбият – татар әдәбиятының нигезе. Орхон-Енисей истәлекләрендә төрки халыкларның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре, аларда тарихның, ышануларның чагылышы. Шәркый жанрлар системасы. Традицияләр, яңачалык. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият. Төрара формалар: сәяхәтнамәләр.

М.Кашкарыйның “Диване-лөгатет-төрк”әсәре (борынгы төрки фольклор һәм язма әдәбиятны өйрәнүдә төп чыганак), Й.Баласагунлының “Котадгу белек”(төрки халыкларның беренче классик поэмасы). Болгар-татар әдәбияты. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы – кешелекнең зирәклек матурлык һәм бөеклек хисенә гимн. Алтын Урда чоры татар әдәбиятында Яңарыш юнәлеше: Котб, С.Сараи, Хәрәзми иҗатлары. Төрки татар әдәбиятында дини-суфичыл юнәлеш.

Казан ханлыгы чоры татар әдәбиятына гомуми характеристика. Казан ханлыгының рус дәүләтенә кушылуы. М.Колыйның фәлсәфи әсәрләре – хикмәтләрдә татар халкындагы кризисның чагылышы. XIX йөздә татар әдәбияты. Г.Курсави, И.Хәлфин, К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, И.Гаспралы һ.б.ның мәгърифәтчелек эшчәнлеге. Г.Кандалый, Акмулла һәм башкаларның иҗатларында реалистик поэзиянең барлыкка килүе. Татар реалистик прозасының барлыкка килүе.

Әдәбиятта Европа тибындагы яңа жанр һәм төрләрнең барлыкка килүе. З.Бигиевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә” әсәре. Татар халкының үсеше һәм яңарышына ихтыяҗ кебек темаларның актуальлеге, татар хатын-кызы язмышы, әйдәп баручы культурасына, шул исәптән рус культурасына йөз тоту. “Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә” әсәренең сюжеты, сюжет элементлары. Әсәрдә образлар системасы. Тема, проблема, идея.

**XX йөз башы татар әдәбияты**

XX йөз башы татар әдәбиятының Көнчыгыш, рус, Европа әдәбиятлары фәлсәфәләре һәм мәдәнияте, казанышларының кушылуы. Ф.Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты. “Хәят” повесте. Әдәбиятта романтик мотивлар. Психологизм. Модернизм һәм аның алымнары.

Г.Камалның “Банкрот” комедиясе, аңа анализ ясау (тематика һәм проблематика, сюжет, композиция, әсәрнең теле) Юмор һәм сатира. “Банкрот” комедиясендә образлар системасы. Әсәрнең актуальлеге. Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж.

**XX йөзнең беренче яртысындагы татар әдәбияты**

1917 нче елдан соң татар әдәбиятының үсеш процессында каршылыклар. Роман жанры традицияләренең активлашуы. М.Галәүнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Мөһаҗирләр” романы (өзекләр)Романның сюжеты, образлар системасы, әсәрдә урын һәм вакыт. Әсәрнең әһәмияте.

Бөек Ватан сугышы, аның татар әдәбиятына йогынтысы. Сугыш чоры поэзиясенең мотивы, образлары, поэтикасы. Г.Кутуйның тормыш юлы һәм иҗаты. “Сагыну” нәсере. Нәсер һәм инверсия турында төшенчә.

М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. “Җырларым, “Тик булса иде ирек”, “Кошчык”, “Ышанма” шигырьләре. Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре.

Ә.Еникинең “Кем җырлады?” хикәясе. Хикәянең сюжеты, катнашучы геройлар. Х.Туфанның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Иҗатының төп этаплары.

Х.Туфанның 40-50нче еллар поэзиясенең лирик юнәлеше. “Кайсыгызның кулы җылы?” шигыре. Лирик герой. Х.Туфанның “Киек казлар” шигырен анализлау. Х.Туфанның күңел лирикасы. Поэтика һәм стиль үзенчәлекләре.

**XX йөзнең икенче яртысында әдәбият.**

Татар әдәбиятының милли традицияләргә кайтуы. Татар халкының традицияләре, милли характер үзенчәлекләрен сәнгати җиткерү. А.Гыйләҗевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Җомга көн кич белән” повесте. “Җомга көн кич белән” повестеның сюжет-композициясе, тел-стиль чаралары. Деталь.Әсәрдәге образлар.

Социалистик реализм юнәлешендә тарихи романнар иҗат итү. Н.Фәттахның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Итил суы ака торур” романы, аның сюжеты. Тарихи роман турында төшенчә. “Итил суы ака торур” романында тема, проблема, идея, пафос. Идеал.

**XX-XXI чигендәге әдәбият (1996-2016чы еллар)**

Милли традицияләрне саклау һәм аларны яңарту проблемасы. Т.Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Кулъяулык” музыкаль драмасы. Музыкаль драма турында төшенчә. Миңнуллинның “Кулъяулык” драмасының сюжет-композициясе, тел-стиль чаралары. Образлар системасы. Мифологик образ.

Кеше һәм җәмгыять конфликты карашыннан ил тормышындагы аерым этапларны сурәтләгән әдәби әсәрләр барлыка килү. Ф.Садриевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Таң җиле” романы. Ф.Садриевның “Таң җиле” романының сюжеты. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. Ф.Садриевның “Таң җиле” романында психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи-иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау.

XX-XXI гасыр чигендә әдәбиятның тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе: совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу, халык тарихының якын һәмерактагы тарихы турында уйлану. Зөлфәтнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Тамыр көлләре”, “Тойгыларда алтын яфрак шавы” шигырьләре. Фәлсәфи лирика. Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус, чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар. Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар.

Барлыгы : 34 сәг**.**